ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СЕЛЕНГУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　Сәләнгеш авылы　　КАРАР

№ 27　　«23 » декабрь 2019 ел

---

2020 елда хөкем ителгәннәр җәзасын үтәү өчен мәҗбүри эшләр төрләрен һәм объектларны билгеләү турында

РФ Җинаять кодексы нигезендә, РФ Җинаять-башкарма кодексының 49 маддәсе 1 өлеше нигезендә, 25 маддәсе 1 өлеше нигезендә Сәләнгеш авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәгәндә, Сәләнгеш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Сәләнгеш авыл җирлеге территориясе чикләрендә: Сәләнгеш авылы, Зүзәй авылы торак пунктларында, җинаять-үтәтү инспекцияләре белән килештереп, мәҗбүри эшләр башкару урыннарын билгеләргә.
2. Торак пунктларны һәм зиратларны төзекләндерү, юл һәм буалар буйларында куакларны кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен чистарту, хезмәт эшчәнлегенең алдан һәм һөнәри әзерлек таләп итми торган башка төрләрен, җинаять-үтәтү инспекцияләре белән килештереп, билгеләргә.
3. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җинаять-үтәтү инспекциясе белән берлектә, Сәләнгеш авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм төзәтү яисә мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларга карата суд карарларын үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.
4. Карарны «Сәләнгеш авыл җирлеге» бүлегендә Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе　　А.Н.Пинин

Кушымта: килештерү кәгазе 1 биттә.

«2020 елда хөкем ителгәннәргә карата мәҗбүри эшләр төрләрен һәм җәза үтәү объектларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 23 декабрендәге 27 номерлы карарына

КИЛЕШТЕРҮ КӘГАЗЕ

«КИЛЕШЕНДЕ»
Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе _____________А.Н. Пинин

«КИЛЕШЕНДЕ»
Россия Федераль хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсенең
Нурлат районара филиалы башлыгы,
эчке хезмәт майоры: ____________ В.Р. Яфизова